ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 122-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 122-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 441-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 3 өлешенең беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 10; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Рәис итеп муниципаль район, шәһәр округы башлыгы (шәһәр эчендәге муниципаль комиссиядә – шәһәр округы җирле администрациясенең территориаль органы җитәкчесе) билгеләнә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары ул үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә әлеге Законга туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре (алга таба – комиссия) эшчәнлеген камилләштерү, шулай ук комиссия рәисләренең статусын һәм абруен күтәрү максатларында эшләнгән.

Муниципаль районнардагы комиссия әгъзалары булып балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) тора, шулай ук башка дәүләт (муниципаль) органнары һәм учреждениеләре вәкилләре, иҗтимагый берләшмәләр, дини конфессияләр вәкилләре, балигъ булмаганнар белән эшләү тәҗрибәсе булган гражданнар, тиешле вәкиллекле органнар депутатлары, башка кызыксынган затлар да торырга мөмкин.

Органнар һәм учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү муниципаль район (шәһәр округы) башлыгы җаваплылыгында була.

Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары статусы исә гамәлдә идарә йогынтысы буенча вәкаләтләр өлкәсе белән чикләнә, чөнки аның эшчәнлеге, кагыйдә буларак, башлыча башкарма комитетның эчке структур бүлекчәләре белән бәйле.

Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү, аларның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеге өчен, профилактика системасы күпкә киңрәк булганлыктан, ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру һәм оператив карарлар кабул итү өчен киңәйтелгән вәкаләтләргә ия зат - комиссия рәисенең статусы югарырак булырга тиеш.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, закон проекты хокук куллану практикасыннан чыгып комиссияләр рәисләрен билгеләп кую тәртибен үзгәртүне күздә тота: әлеге вазыйфага муниципаль районда – муниципаль район башлыгын, шәһәр округында – шәһәр округы башлыгын, шәһәр эчендәге муниципаль комиссиядә - шәһәр округы җирле администрациясенең территориаль органы җитәкчесен билгеләп куярга тәкъдим ителә.

Комиссия рәисенең статусын күтәрү ведомствоара хезмәттәшлек һәм тәкъдим ителә торган чараларны гамәлгә ашыру механизмнарын көчәйтеп, профилактика системасының барлык субъектларының үзара хезмәттәшлеген нәтиҗәлерәк җайга салырга мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 елның 24 сентябрендәге 798 номерлы карарына үзгәреш кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслау таләп итми.